Карар проекты буенча ачык тыңлаулар башлану турында

**ХӘБӘР ИТҮ**

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турындагы боерыгы проекты буенча ачык тыңлаулар башлануы турында хәбәр итәбез.

Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгы карары;
2) 1 нче кушымта - җир кишәрлегенең ситуация планы;
3) 2 нче кушымта-комиссия составы

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетына 16:09:140101:370 кадастр номерлы, мәйданы 1 846 кв. м булган, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Иске Кырлай авыл җирлеге, Югары Әзәк ав., Гомәр Бәширов ур., 20 йорт адресы буенча урнашкан - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең универсаль торак зонасында (Ж-У) “Дини йолаларны гамәлгә ашыру” җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында ачык тыңлауларны үткәрү ситуацион план нигезендә (1 нче кушымта), 2026 елның 14 сентябренә 14.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча билгеләнгән: Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12 йорт (кече зал).

Ачык тыңлауларда катнашучылар даирәсе:

җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карарлар проектлары, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турындагы карарлар проектлары буенча гавами тыңлауларда катнашучылар түбәндәге гражданнар була:

үзләренә карата әлеге проектлар әзерләнгән җир кишәрлеге яисә капиталь төзелеш объекты урнашкан территориаль зона чикләрендә даими яшәүчеләр;

шушы территориаль зона чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;

әлеге проектлар әзерләнгән җир кишәрлегенә якын җир кишәрлекләре чикләрендә даими яшәүче гражданнар;

мондый җир кишәрлекләренең яисә аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;

әлеге проектлар әзерләнгән капиталь төзелеш объектының бер өлеше булган урыннарның хокук ияләре;

мондый тискәре йогынты куркынычы янаган җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре - җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төре әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясарга мөмкин булган очракта.

Гавами тыңлаулар үткәрелә торган территория: Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Арча шәһәре.

Ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен ачу урыны һәм датасы: Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12 йорт, 2026 елның 28 августы.

Проект экспозициясен үткәрү вакыты: 2026 елның 11 сентябрендә 12:00 сәгатькә кадәр.

Экспозицияне карарга мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат: көн саен эш көннәрендә 12:00 сәгатькә кадәр.

Ачык тыңлауларда катнашучыларның проектка кагылышлы тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне кертү тәртибе, сроклары һәм формасы: гавами тыңлаулар темасына кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12 йорт, белешмәләр өчен телефон: 3-21-33, 3-06-28, (шимбә һәм якшәмбедән тыш көн саен) 2026 елның 11 сентябрендә 12.00 сәгатькә кадәр.

Ачык тыңлауларда катнашучылар җыелышының датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат: 2026 елның 14 сентябрендә 14.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12 йорт (кече зал).

Ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект урнаштырылачак рәсми сайт (http://arsk.tatarstan.ru) турында мәгълүмат һәм аңа мәгълүмати материаллар: Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннардагы мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Түбән Мәтәскә ав., Тукай ур., 2 й.; Казиле ав., Җиңү ур., 11 й.; Югары Мәтәскә ав., Азино ур., 22 й.; Мөндеш ав., Татарстан ур., 46 й.; Иске Кырлай ав., Үзәк ур., 12а й.; Югары Әзәк ав., Г. Бәширов ур., 21 й.; Өтнә ав., С. Сәйдәшев ур., 16а; Иске Иябаш ав., М. Җәлил ур., 41 йорт.

Әлеге хәбәрнамәне 2026 елның 21 августына кадәр халыкка җиткерергә.

Арча муниципаль район башлыгы урынбасары, комиссия рәисе ____________ Р.Д.Мөхәмәдияров

Юридик мәсьәләләр буенча бүлек җитәкчесе ____________ Л.Г.Сәгыйтова

Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе ____________ И.М.Хәсәнов

Арча районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең финанс-икътисад бүлеге җитәкчесе ____________ И.Г.Шәрифуллин

Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы ____________ Ф.Ф.Лотфуллин